КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 21 июнь г.Казань № 407

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының еракта урнашкан һәм керергә авыр булган торак пунктлары исемлеген раслау турында” 2005 ел, 29 декабрь, 648 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының еракта урнашкан һәм керергә авыр булган һәм аларда оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр, түләү карталарын файдаланып, тикшерү-касса техникасын кулланмыйча исәп-хисап һәм (яки) кулда булган акча белән исәп-хисап ясый ала торган торак пунктлары исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының еракта урнашкан һәм керергә авыр булган торак пунктлары исемлеген раслау турында” 2005 ел, 29 декабрь, 648 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 20 ноябрь, 558 нче; 2007 ел, 26 март, 103 нче; 2007 ел, 29 апрель, 165 нче; 2007 ел, 16 июль, 299 нчы; 2008 ел, 28 гыйнвар, 35 нче; 2008 ел, 29 сентябрь, 711 нче; 2009 ел, 8 май, 288 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының еракта урнашкан һәм керергә авыр булган һәм аларда оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр, түләү карталарын файдаланып, тикшерү-касса техникасын кулланмыйча исәп-хисап һәм (яки) кулда булган акча белән исәп-хисап ясый ала торган торак пунктлары исемлегенә, аны яңа редакциядә бәян итеп (теркәлгән), үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\407.docx